СИШӘМБЕ
2
МАРТ
1943 ел.
№ 50 (6772)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫН КИҢ ҖӘЕЛДЕРИК

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның 23 нче февраль приказы фронтта һәм тылда, илебезнең барлык почмакларында моңа кадәр һич тә күрелмәгән энтузиазм тудырды. Дошманны җиңүгә, сугышта һәм хезмәттә тагын да көчлерәк һөҗүмгә, яңадан-яңа геройлыкларга рухландыра торган бу тарихи документның һәрбер сүзе йөрәкләргә тирән үтеп керә. Кызыл Армиянең фронттагы уңышлары тылдагы хезмәт ияләрен чиксез шатландыра, фронт өчен коралларны, сугыш припасларын, азык продуктларын тагын да күбрәк җитештерүдә аларга яңа көч, яңа дәрт бирә.

Предприятиеләрдә, колхоз-совхозларда иптәш Сталинның приказына багышланган митинглар гаять зур күтәренкелек белән үттеләр. Барлык коллективлар бу тарихи приказга җавап итеп үз өсләренә яңа йөкләмәләр алалар, стахановчы вахталарга басалар. Тыл сугышчылары, барлык көчне фронтка ярдәмгә лозунгысы астында эшләп, юлбашчыбызның чакыруына тагын да гүзәлрәк практик эшләр белән җавап бирәләр.

Ике орденлы 92 нче номерлы завод коллективының иптәш Сталинга язган хаты барлык газеталарда да басылып чыкты. Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган социалистик ярышка кушылганда алган йөкләмәләрен намус белән үтәп чыккан, завод хезмәт ияләренең средстволары исәбенә, планнан тыш, 10 полкны пушкалар белән һәм 3 танк бригадасын кораллар белән тәэмин иткән бу алдынгы заводның эшчеләре, инженер-техник работниклары һәм хезмәткәрләре үзләренең хатларында, илебездәге барлык предприятиеләргә мөрәҗәгать итеп, иптәш Сталинның приказына җавап йөзендә Беренче Май алды ярышын җәеп җибәрергә чакыралар.

Социалистик ярыш — барлык тармакларда да зур уңышлар яулап алуны, фронтка булышлык итү эшен тагын да көчәйтүне тәэмин итүче, сыналган гүзәл метод ул. Эшчеләр, колхозчылар һәм барлык хезмәт ияләре, ярышып эшләп, планнарны, заданиеләрне, нормаларны арттырып үтиләр, хезмәт җитештерүчәнлеген өзлексез күтәрәләр, продукциянең сыйфатын яхшырталар, электр энергиясенә, ягулыкка, материалларга, чималга шактый экономия ясауга ирешәләр. Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә илебездә гаять киң җәелеп киткән социалистик ярышның йомгаклары моны бик ачык раслый.

Хәзер, ирешелгән уңышларны ныгыту, алда аларны тагын да арттыру өчен Беренче Май алды ярышын киң колач белән җәелдерү, яңа йөкләмәләр алып аларны намус белән үтәү һәм арттырып үтәү өчен көрәшү, фронтка булышлыкны тагын да көчәйтү, шуның белән явыз дошманның тәмам тар-мар ителү сәгатен тагын да якынайту — бөек юлбашчыбызның приказына бердән-бер лаеклы җавап булып тора.

Беренче Май алды ярышын үрнәк төстә һәм чын-чыннан массовый итеп оештыру, алынган йөкләмәләрнең тулысынча үтәлүен тәэмин итү буенча партия, комсомол, профсоюз оешмаларына гаять җитди һәм җаваплы бурыч йөкләнә. Бу бурыч, һичшиксез, большевикларча үтәлер.

Социалистик ярыш байрагын тагын да югарырак!

Республикабызның эшчеләре, колхозчылары һәм барлык хезмәт ияләре! Беренче Май алды ярышына барыгыз да бердәм рәвештә кушылыгыз! Үзегезгә тапшырылган участокта героик хезмәтегез белән яңа һәм зур җиңүләр яулап алыгыз! Фронтка булышлыкны тагын да бик күп тапкыр көчәйтү буенча үзебезнең практик эш нәтиҗәләребез белән Кызыл Армиягә, илгә, бөек Сталинга рапортлар әзерлик!

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

ДЕМЯНСК РАЙОНЫНДА ДОШМАННЫҢ НЫГЫТЫЛГАН ПЛАЦДАРМЫН БЕТЕРҮ

1941 нче елның сентябрендә немец-фашист гаскәрләр, ИЛЬМЕНЬ күленнән көньяк-көнчыгыштарак фронтны өзеп, немецларның 16 нчы армиясе көчләре белән ЗАЛУЧЬЕ—ЛЫЧКОВО—ДЕМЯНСК районын алып, шуннан көнчыгышка таба ВЕЛЬЕ һәм СЕЛИГЕР күлләре ярларына кадәр килеп җитә алганнар иде. Шуннан соңгы 17 ай буена дошман үзе басып алган бу плацдармны ныклык белән һәм бик тырышып үз кулында тотып калырга омтылды һәм аны ныгытылган куәтле районга әйләндереп, «Демянск крепосте» дип атады. Немецлар безнең гаскәрләрнең төньяк группасының иң әһәмиятле коммуникацияләренә каршы ударны җәелдерү өчен шушы ныгытылган районнан файдаланырга уйладылар. Шул ук вакыт эчендә бу район берничә тапкырлар бик каты сугышлар барган мәйдан булды һәм анда немецларның дивизияләре тар-мар ителеп килде.

Шушы көннәрдә маршал Тимошенко командалыгындагы Төньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре немецларның 16 нчы армиясенә каршы һөҗүмгә күчтеләр. Сугышлар барышында безнең гаскәрләр, күп кенә участокларда дошманның көчле итеп ныгытылган полосасын өзеп, немец-фашист гаскәрләрнең ике катлы чолганып алынуларының реаль куркынычын тудырдылар. Дошман, чолганып алыну куркынычын сизеп, безнең гаскәрләрнең удары астында ашыгыч рәвештә көнбатышка чигенә башлады.

Сугышларның 8 көне эчендә безнең гаскәрләр, дошманны туктаусыз куып барып, халык яши торган 302 пунктны, шул исәптән ДЕМЯНСК шәһәрен һәм район үзәкләреннән ЛЫЧКОВОНЫ һәм ЗАЛУЧЬЕНЫ азат иттеләр. 2.350 квадрат километр зурлыктагы территория дошманнан чистартылды. Сугышларның 8 көне эчендә безнең гаскәрләр 3.000 немец солдатын һәм офицерын плен алдылар.

Шул ук вакыт эчендә түбәндәге трофейлар КУЛГА ТӨШЕРЕЛДЕ: самолетлар—78, танклар—97, төрле калибрдагы орудиеләр—289, пулеметлар—711, шулай ук бик күп сугыш припаслары һәм башка төрле сугыш милекләре.

Сугыш кырында дошман 8.000 нән артык үле гәүдәләрен калдырды.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Совет Информбюросыннан

28 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

28 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошманга каршы ут сугышы алып бардылар. Н-че берләшмә артиллеристлары немецларның дистәләрчә ДЗОТларын һәм блиндажларын җимерделәр; 4 артиллерия батареясының утын бастырдылар һәм җыелып тора торган дошман пехотасын таркаттылар. Безнең разведчикларның бер отряды төнлә белән дошман тылына барып чыктылар һәм бер зур артиллерия складын шартлаттылар.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак Н-че часть, дошманның көчле ут каршылыгын бастырып, алга таба барды. Немецлар, югалткан позицияләрен кайтару теләге белән, берничә тапкыр контратака ясадылар, ләкин уңышка ирешә алмадылар. Бу сугышта безнең подразделениеләр 300 гә якын гитлерчыны юк иттеләр.

* * *

Краматорскаядан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошман танкларының һәм мотопехотасының тагын бер контратакасын кире кайтардылар. Сугыш нәтиҗәсендә немецларның 8 танкысы зарарланды һәм яндырылды, пехота төялгән 19 автомашинасы юк ителде. Н-че берләшмә соңгы сугышларда немецларның 20 тимер юл эшелонын һәм 30 складын юк итте.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта совет подразделениеләре дошманның ике ротага якын пехотасын һәм 11 автомашинасын юк иттеләр. 5 орудие, 19 пулемет һәм 2 сугыш милекләре склады кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең танкистлар, дошманны куып барып, немецларның бер пехота колоннасын тар-мар иттеләр. Дошманның 2 танкысы, танкка каршы ата торган 5 орудиесе юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Курскидан көнбатыштарак безнең бер танк часте, омтылышлы атака нәтиҗәсендә, халык яши торган бер зур пунктны алды. 200 гә якын гитлерчы юк ителде. 4 орудие. танкка каршы ата торган 7 мылтык, 9 пулемет, бер сугыш припаслары складь һәм бер кием склады кулга төшерелде.

* * *

Кубаньда Н-че берләшмә частьлары алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. 6 орудие, 21 заряд ящигы, 100.000 патрон, йөк төялгән 60 повозка һәм 90 ат кулга төшерелде.

* * *

Карел-Фин ССР ның бер районында хәрәкәт итүче «Железняк» исемле отрядның бер группа партизаннары февраль башында ак финнарның бер отрядын тар-мар иткәннәр. Совет патриотлары, обозны озатып баручы солдатларны үтереп, шактый күп сугыш припаслары, киемнәр һәм азык кулга төшергәннәр. Карел-Фин партизаннарының «Буревестник» отрядынан бер группа бер авылда дошман гарнизоның юк иткән һәм 800 метр телефон-телеграф чыбыгын кисеп алган.

* * *

Орел- өлкәсе, Малороссово авылыннан чигенгән чакта немец-фашист кабахәтләр бер группа кешеләрне Иван Давыдов йортының подвалына кертеп бикләгәннәр һәм йортны яндырганнар. Давыдов үзе, аның хатыны һәм балалары—16 яшьлек Мария, 15 яшьлек Александра, 13 яшьлек Анна, 8 яшьлек Николай, 6 яшьлек Алексей, 3 айлык бер бала, 70 яшьлек Александра Волкова һәм башка кешеләр һәлак булганнар.

* * *

Мостор-Сараево тимер юл районында һөҗүм итүче Югославия партизаннары сугышларның 6 көне эчендә дошманның берничә гарнизонын юк иткәннәр. Патриотлар 800 дән артык итальян солдатын һәм 25 офицерны үтергәннәр, ә 960 солдатны һәм офицерны плен алганнар. Трофейлар кулга төшерелгән. Шулар арасында 16 танк, 15 орудие, 16 миномет, 216 станоклы пулемет һәм кул пулеметлары, 10 мең граната, миллион ярым патрон һәм төрле сугыш милекләре бар. Дони Лопац районында партизаннар оккупантларның бер колоннасын тар-мар иткәннәр һәм итальяннарның 3 танкысын кулга төшергәннәр. Любляныдан көнбатыштарак партизаннар отряды 40 дошман солдатын һәм офицерын, шул исәптән Полхов Градец шәһәренең итальян комендантын юк иткән.

28 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

28 нче февральдә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

21 нче февральдән 27 сенә кадәр үткән атнада һава сугышларында һәм дошман аэродромнарында немецларның 168 самолеты юк ителде. Шул ук вакыт эчендә без 87 самолет югалттык.

* * *

27 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар һәм 14.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр үзләре алган позицияләрне ныгыттылар һәм аерым участокларда дошманга каршы ут сугышы алып бардылар. Н-че берләшмә бер көн эчендә 150 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын юк итте. Гвардия лейтенанты Глуховның йөртүче-механик өлкән сержант Борисов, башня укчысы сержант Носиков һәм пулеметчы сержант Писарев составындагы танк экипажы, дошман урнашкан урынга бәреп кереп, берничә дистә гитлерчыны кырып ташлады һәм 8 орудие кулга төшерде. Пулеметчы иптәш Догадин берничә ату белән немецларның бер самолетын бәреп төшерде.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак Н-че берләшмә частьлары сугышларның ике көне эчендә 200 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырып ташладылар, дошманның 3 танкысын сафтан чыгардылар һәм 2 самоход орудиесен кулга төшерделәр. Икенче бер участокта безнең сугышчылар немецларның бер батальон пехотасының контратакасын кире кайтардылар. Гитлерчылар авыр югалтуларга дучар ителделәр һәм элекке позицияләренә чигенделәр.

* * *

Краматорская районында безнең гаскәрләр дошман танкларының һәм мотопехотасының бик каты контратакаларын кире кайтардылар. Немецлар ашыгыч рәвештә яңа частьлар китерәләр һәм

(Ахыры 4 нче биттә).

СССР Верховный Советы Президиумыннан

СССР Верховный Советы Президиумы Совет дәүләтен күренекле төзүчеләрдән берсенең, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Урынбасары һәм Үзбәкстан ССР Верховный Советы Президиумы Председателе Юлдаш Ахунбабаевның үлүе турында тирән кайгы белән белдерә.

СССР Верховный Советы Президиумы

Ватан сугышының хәлиткеч моменты

Г. АЛЕКСАНДРОВ

Гитлер армияләренә каршы өч айлык һөҗүм барышында безнең гаскәрләр тарафыннан ирешелгән уңышлар, 23 нче февральдә безнең ватаныбыз һәм бөтен дөньядагы азатлык сөюче барлык халыклар билгеләп үткән юбилейгә тулысынча лаеклы. Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының чирек гасыр яшәвен, немец-фашист армияләрен җиңү өчен ныклы фундамент яулап алып безнең сугышчыларыбыз эшләгәннән дә тантаналырак һәм гүзәлрәк итеп билгеләү мөмкин түгел.

Үткән 25 ел эчендә Ленин һәм Сталин, безнең партиябез, совет халкы ватаныбызның кораллы көчләрен төзеделәр һәм үстерделәр. Шулардан башка Кызыл Армиянең бүгенге җиңүләре мөмкин булмас иде. Хәзерге заман армиясен төзү буенча озак еллар армый-талмый эшләү безгә сугышның беренче этабында немец-фашист бандаларын хәлсезләндерергә һәм тоткарларга, аларны илебезнең үзәк промышленность районнарына җибәрмәскә, безнең башкалабызны басып алу буенча аларның планын өзәргә мөмкинлек бирде, безгә сугышның барышында көчләрне җыярга, ә аннары дошманга удар ясарга, аңа гаять зур югалтулар китерергә һәм аның урдаларын көнбатышка куарга мөмкинлек бирде.

Гитлер Германиясенә каршы ватан сугышының егерме ае бик ачык мөһим этапларга бүленә.

Беренче этап—1941 нче елның җәе һәм көзе. Бу вакытта Советлар Союзына көтмәгәндә һөҗүм иткән немец гаскәрләре Кызыл Армияне кысрыклауга һәм илебезнең шактый районнарын басып алырга ирештеләр.

Кызыл Армия, дошманны бик нык хәлсезләндереп, үзенең көчләрен туплап, оккупантларга каршы көрәштә мәгълүм тәҗрибә алып, үзенең резервларын әзерләп һәм җәелдереп, үзе һөҗүмгә күчте һәм немецларга күп кенә көчле ударлар ясады, 1941—1942 нче елның кышында Москвага килү юлларында һәм фронтның күп кенә башка участокларында немецларның сайланма гаскәрләрен тармар итте. Ватан сугышының чираттагы этабы шунда башланды.

1942 нче елның җәендә, Европада икенче фронт юклыктан файдаланып, немецлар барлык вассал илләрдән һәм оккупацияләнгән илләрдән үзләренең резервларын җыйдылар, Европадагы күпчелек илләрнең промышленностен сугыш өчен эшләүгә күчерделәр, Германиядә 17 дән алып 55 яшькә кадәр булган контингентка мобилизация ясадылар һәм, шулай итеп, безгә каршы яңадан шактый көчләр куюга, көньяк-көнбатышта һәм көньякта безнең гаскәрләрне кысрыклауга һәм күп кенә мөһим районнарны басып алуга ирештеләр. Ләкин 1942 нче елның җәендәге һәм көзендәге бу авыр сугышларда да Кызыл Армия, фашистик ерткычның юлын бүлеп, немецларның планнарын өзде. «Севастопольнең һәм Одессаның героик оборонасы истәлеген, Москва янында һәм Кавказ таулары алдында, Ржев районында һәм Ленинград янында булган каты сугышлар истәлеген, Сталинград стеналары янында сугышлар тарихындагы иң зур сугыш истәлеген безнең халкыбыз мәңге саклар» (Сталин).

1942—1943 нче елның кышында ватан сугышының барышында яңа, **хәлиткеч момент** башланды, советлар җиреннән **дошманны масса төсендә куу** башланды.

Сугыш барышында беренче тапкыр буларак, Кызыл Армиянең һөҗүм хәрәкәтләре шундый гаять зур колач алдылар. Дошман гаскәрләренә авыр югалтулар китерелде. Кызыл Армия үзенең һөҗүме белән дошманның барлык хәрби, политик һәм экономик исәпләрен астын-өскә китерде. Ул илебезнең күп кенә экономик һәм хәрби-стратегик районнарын немец-фашист басып алучылардан азат итте, сугыш хәрәкәтләрен дәвам иттерү өчен бик уңайлы позицияләрне дошман армияләреннән тартып алды. Немецлар Грозный һәм Баку нефтенә кул сузганнар иде; Кызыл Армия Төньяк Кавказда немец армияләрен җиңелүгә дучар итте һәм бу районнарны дошманның басып алу куркынычын бетерде. Немецлар Кубань, Дон, Курск һәм Воронеж өлкәләренең икмәгенә кул сузганнар иде; безнең гаскәрләр бу районнарда оккупантлар армияләрен җимерделәр һәм аларны еракка, көнбатышка алып ташладылар. Немецлар Донбасстагы заводларны һәм шахталарны аякка бастырып эшкә җибәрергә уйлаганнар иде; героик Кызыл Армия инде Донбассның бер өлешен азат итте һәм монда дошманга ударлар ясауны дәвам итә. Сталинград, Краснодар, Нальчик, Моздок, Ростов, Ворошиловград, Харьков, Воронеж, Курск кебек шәһәрләрне немецлар үзләренең киләчәктәге һөҗүмнәре өчен алдагы сугыш хәрәкәтләрендә төп хәрби-стратегик база ролен уйнарлар дип исәп тоттылар; Кызыл Армия бу районнардан дошманны куып чыгарды, бу шәһәрләрне оккупантлардан азат итте һәм аларны киләчәктәге уңышлы сугышлар өчен үзенең башлангыч терәк пунктлары итеп әверелдерде. Хәзер бөтен дөнья Совет—Германия фронтындагы вакыйгаларның барышын гаять зур игътибар һәм өмет белән күзәтә.

Ватан сугышының бу егерме ае эчендә нәрсә булды соң? Сугышучы дәүләтләрнең көчләр чагыштырмасы ничек үзгәрде?

Һәрбер сугышучы якның хәлендәге үзгәрешләрнең мәгънәсе, барыннан да элек, шунда ки, немецлар командованиесенең стратегик планнарының берсе дә тормышка ашырылмады һәм СССР га каршы сугышның егерме аеннан соң Гитлер Германиясе, гәрчә зур территория басып алган булса да, сугыш башлангандагыга караганда көчсезрәк булып әверелде. Кызыл Армиягә килгәндә исә, ул дошманны тоткарлап кына калмады, бәлки безнең халкыбызга кайчан да булса сугышырга туры килгән барлык дошманнарның иң көчлесенә каршы авыр, канлы сугышта күп тапкыр көчлерәк, тәҗрибәлерәк булып әверелде, дошманга авыр җиңелүләр китерде.

Бу вакыт эчендә фронтта нинди кискен үзгәрешләр булып үткәнлеккә, Совет Верховный Баш Командованиесенең планнарын уңышлы рәвештә тормышка ашыручы безнең гаскәрләрнең сугыш хәрәкәтләре барышында нинди җитди борылышка ирешүенә ышану өчен Кызыл Армиянең өч ай буена һөҗүм итү юлын картадан карау гына да җитә.

Кызыл Армия Сталинград янында, Төньяк Кавказда, Кубаньда, Воронеж һәм Донның урта агымы районында немецларны тар-мар итте, Украинаны дошманнан уңышлы рәвештә азат итә, фронтның башка участокларында аңа ударлар ясый. Кызыл Армиянең һөҗүмен тоткарларга маташып, немецлар оккупацияләнгән илләрдән гаскәрләрен алырга мәҗбүр булалар. Соңгы вакытларда гына да алар Германиядән генә түгел, бәлки Франциядән, Голландиядән, Бельгиядән һәм Балканнан 30 дан артык яңа дивизияләрен алдылар һәм аларны ашыгыч рәвештә Совет—Германия фронтына җибәрделәр. Немецларның бу яңа частьлары ут линиясенә килеп җитү белән, Кызыл Армия үзенең җиңүле һөҗүмен дәвам иттергән хәлдә, аларны кыйный.

Сугыш сәнгате тарихы әле мондый масштаблардагы һәм мондый нәтиҗәле һөҗүм хәрәкәтләрен белми иде. Иптәш Сталин үзенең 23 нче февральдәге приказында, Кызыл Армия, соңгы өч ай эчендә 1.500 километр озынлыктагы фронтта һөҗүмне җәелдереп, зур уңышларга ирешә, диде. Кызыл Армия дошманның 112 дивизиясен җимерде, сугышларда дошманның 700.000 солдат һәм офицерларын кырды, 300 меңнән артык пленныйлар алды. Сугыш башланганнан бирле барлыгы 9 миллионга якын немец-фашист солдатлары һәм офицерлары сафтан чыгарылды. Шулардан кимендә 4 миллионы үтерелде.

Шулай итеп, кыска гына вакыт эчендә Гитлерның гаять күп сандагы сайланма гаскәрләре сафтан чыкты. Бу фактның әһәмиятен бәя биреп бетерү кыен. Беркайчан да әле хәзерге заманның дөнья сугышында да, Европада XIX һәм XX нче гасырлар сугышларында да, шушы кадәр кыска срок эчендә гаскәрләрнең мондый гаять зур массасының сафтан чыкканы юк иде.

Иптәш Сталин, немецлар командованиесе гаскәрләрдәге бу гаять зур югалтуны каплау өчен барлык чараларны күрергә маташачак, дип күрсәтте. «Ләкин, беренчедән, немец армияләренең йомшак урыны—кешеләр резервлары җитешмәүдә, шунлыктан бу югалтуларның нинди чыганаклардан алып капланачагы билгесез. Икенчедән, әгәр дә хәтта немецлар кирәк кадәр сандагы кешеләрне барлык дөрес булган һәм дөрес булмаган юллар белән кырып-себереп җыярлар дип уйлаганда да әле аларны җыю һәм өйрәтү өчен күп вакыт кирәк булачак. Ә вакыт көтми» (Сталин).

Кызыл Армия, һөҗүм иткән хәлдә, дошманның масса күләмендәге коралларын юк итте һәм үз кулына төшерде. Шушы вакыт эчендә немецлар 7 меңнән артык танкларын, 4 мең самолетларын, 17 мең орудиеләрен һәм зур санда башка коралларын югалттылар. Бу гаять зур югалтуларны тулыландыру өчен немецларга, аеруча Германиянең материаль һәм кеше ресурслары тизлек белән бетә барганда, аз вакыт кирәк булмаячак, ә вакыт көтми.

Безнең гаскәрләр, гаять каты сугышлар белән алга барып, Сталинградтан көнбатышка таба 600 километрга якын ара үттеләр, гаять зур совет территориясен дошман оккупациясеннән азат иттеләр. Владикавказдан алып Кубань аша һәм Таганроггтан бераз төньяктагы Матвеев Курганга кадәр, илебезнең көньяк районнары аша Кызыл Армия үткән юл тагын да бөегрәк. Шулай итеп, көньякта безнең гаскәрләр тарафыннан кырылган миллионнарча немец солдатлары һәм офицерларының тормышы исәбенә сугышның бер елдан артык вакыт эчендә немецлар басып алган җирне, Кызыл Армия өч айлык уңышлы һөҗүм белән яулап алды!

Күп миллионлы армиягә каршы һөҗүмнең мондый темпларын сугышлар тарихы белми!

Безнең гаскәрләрнең уңышлары, алар Европада икенче фронт булмаган шартларда, Кызыл Армия сугышның бөтен авырлыгын үз җилкәсендә алып барган шартларда ирешелгәнлектән, бигрәк тә әһәмиятлеләр.

Кызыл Армиянең һөҗүме безнең дошманнарыбыз лагеренда шашыну, курку һәм югалып калу дулкынын китереп чыгарды, ә безнең дусларыбыз лагеренда—соклану һәм шатлык, җиңүгә ышанычның яңадан артуын китереп чыгарды. Швециядә чыга торган «Арбетарен» газетасы шушы көннәрдә баш мәкалә чыгарды. Анда болай диелгән: «Русларның һөҗүме куркыныч күләмнәргә керә. Гитлер большевизмны Урал артына куарга вәгъдә иткән иде, ләкин руслар броняланган йодрыкларын туп-туры немецларның борыннарына китереп төрттеләр, һәм эш бөтенләй башка юнәлеш алды... Германиянең җиңә алмаячагы ачык».

АКШ тагы зур тарихи журнал, совет гаскәрләренең уңышларына бәя биреп, дошманның варварлык методларына каршы көрәштә Кызыл Армия яңа хәрби фән, яңа стратегия һәм тактика төзеде, бу фән Советлар Союзының җиңүен тәэмин итә һәм киләчәктәге буыннар СССР ның үз дошманына каршы көрәше тәҗрибәсен җентекләп өйрәнәчәкләр, дип язды. «Хәзер бара торган гаять зур бөтен дөнья кризисының тарихы тәмам язылып беткәч, — дип яза аннары журнал,— бөтен дөнья күләмендәге конфликтта кайчан да булса халык юлбашчысы тарафыннан кулланылган стратегик алымнарның иң гүзәлләреннән берсен куллану ярдәме белән цивилизация дөньясын саклап калган кеше сыйфатында Сталин килеп басачак».

* * *

Сугышның перспективалары өчен Кызыл Армиянең уңышлары гаять әһәмиятле. Иптәш Сталин Кызыл Армиянең 25 еллыгына чыгарган приказында моны аеруча күрсәтте: «Бу бөек сугышларда безнең батыр сугышчыларыбыз, командирларыбыз һәм политработникларыбыз Кызыл Армиянең сугышчан байракларын мәңгелек дан белән бизәделәр һәм немец фашистлары армияләрен җиңү өчен ныклы нигез салдылар».

Кызыл Армиянең дошманга каршы озак һәм героик көрәше үзенең нәтиҗәләрен бирде. Советлар Союзы үзенең гаять зур эчке көчләрен җәеп җибәреп җиңү өчен кирәкле шартларны булдырды. Сугыш барышында мөһим борылыш башланды. Сугыш аеруча җаваплы һәм хәлиткеч моментка керде. Безнең халкыбызның бурычы һәм Гитлер Германиясенә каршы көрәшү өчен Советлар Союзы белән берләшкән азатлык сөюче барлык халыкларның бурычы шуннан гыйбарәт ки, хәзер барлыкка килгән уңайлы сугыш обстановкасын тулысынча файдаланырга, Гитлер сугыш машинасының куәтен тәмам җимерергә, Гитлер армиясен, Гитлер дәүләтен, Гитлерның Европадагы «яңа тәртибен» юк итәргә.

Кызыл Армия һөҗүменең уңышлары уңае белән гитлерчыларның акырынулары гадәттән тыш характерлы. Немецлар Польшаны, Бельгияне, Голландияне басып алгач, алар тантаналы рәвештә, имештер, Германиянең хәле бу дәүләтләрне алганчыга кадәр булганга караганда «катылгысыз», тагын да ныграк булып әверелде, дип белдерделәр.

(Ахыры 3 нче биттә).

ВАТАН СУГЫШЫНЫҢ ХӘЛИТКЕЧ МОМЕНТЫ

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Аннары Францияне, Балканны басып алгач алар Германиянең хәле тагын да яхшыру турында кычкырдылар. Аннары совет җиренә бәреп кергәч, алар 1941 нче елның җәендә, бүгеннән башлап Германия җиңелмәслек, дип дистәләрчә белдерүләр игълан иттеләр.

Сугышның өч елы буена шулай булды...

Менә Германия сугышның 4 нче елына керде. Һәм нәрсә булды соң? Гитлерчылар бандасы башлыкларыннан берсе—Геббельс — үзенең халык алдындагы чыгышында, Германия моннан өч ел элек Европа сугышын башлаган вакыттагыга караганда хәзер авыррак хәлдә, дип икърар итәргә мәҗбүр булды. Безнең ватаныбыз территориясенә бәреп кергәч һәм монда үзләренә тиешле удары алгач, немецлар «җиңүле» сугышның дүртенче елында, кинәт, хәзер үзләренең хәле һәлакәткә якын, дип акырына башладылар. Бу белдерүләр үз резервларының калдыкларын валчыклап җыю өчен, хәтта 10 яшьтән алып малайларны да хәрби эшләрдә файдалану өчен учетка алып, хәзер немецлар үткәрә торган «тоталь мобилизация» кебек үк, үзләре турында үзләре сөйлиләр.

Табигый буларак, немец солдатларының һәм Германия халкының настроениесе дә, мораль рухы да башкача булып әверелде. Советлар Союзы территориясендә алга баруның җиңеллеге турында гитлерчыларның хыяллары Кызыл Армиянең ударлары белән җимерелә. Аларның җиңүгә булган ышанычлары тизлек белән бетә бара. Германиянең халыкара хәле дә җитди рәвештә начарланды. Ул үзенең тышкы политик резервларын инде тотып бетерде һәм соңгы ел эчендә бер генә дәүләтне дә үз ягында сугышырга котырта алмады. Үзенең «сыналган» вассаллары белән дә Германиянең мөнәсәбәтләре начарлана. Советлар Союзына каршы Гитлер тарафыннан ташланган Румыния, Италия һәм Венгрия армияләре Совет—Германия фронтында тулысынча тар-мар ителделәр.

Фронтта шундый җитди җиңелүләргә дучар булып, гитлерчылар котыртынган демагогия тараталар, бер яктан, Советлар Союзы халыклары арасында, икенче яктан, Англия һәм Америка халыклары арасында ышанмаучылык тудырырга маташалар, азатлык сөюче халыкларны Европаны большевиклаштыру белән куркытырга маташалар. Ләкин гитлерчыларның бу ярсулы кампанияләре дә аларга һич тә файда китерми. Аларның мошенниклык демагогияләре бары тик фашистик Германиянең югары катлауларында ышанмаучылык хөкем сөргәнлекне генә раслыйлар. Азатлык сөюче халыклар арасында үзара ышанмаучылык тудыруга немецларның маташуларына килгәндә исә, моңа иптәш Сталин бик әйбәт җавап бирде: «Кызыл Армия—барлык илләрдәге халыклар арасында тынычлыкны һәм дуслыкны саклау армиясе. Ул чит илләрне басып алу өчен түгел, бәлки Советлар иле чикләрен саклау өчен төзелде. Кызыл Армия барлык халыкларның хокукларына һәм бәйсезлегенә һәрвакытта да ихтирам белән карады». Немецларның демагогик һәм кызганыч көчәнүләре Гитлерга каршы коалиция илләрендәге дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренең, барлык азатлык сөюче халыкларның авторитетлы вәкилләренең кискен отпорына очрый.

* * *

Кызыл Армиянең өч айлык һөҗүме вакытындагы сугыш хәрәкәтләренең фактлагы йомгаклары күз алдында. Җәзаланмыйча бөтен Европаны диярлек талаучы һәм бөлдерүче фашистик урдаларга каршы көрәштә Кызыл Армия гаять зур җиңүләргә иреште.

Большевиклар, вакыйгалар чынбарлыкта нинди булсалар аларны шундый итеп күрә белүләре белән, һәрвакытта аерылып тордылар. Иптәш Сталин һәрвакыт безнең партиябезне, безнең халкыбызны сугышның реаль барышын һәм аның перспективаларын, үзенә ялган хыяллар булдырмыйча, исәпкә алырга өйрәтә. Без хәзерге вакытта җәелеп бара торган сугыш хәрәкәтләренә аек рәвештә карарга тиешбез. Бу исә, имештер, дошман армиясе инде бетерелде, дигән фикер белән үзеңне тынычландыруга юл куярга ярамый, дигән сүз. Иптәш Сталинның, немец басып алучыларга каршы көрәш бары тик җәелә һәм кабына гына бара, дигән сүзләрен һәрвакыт истә тотарга кирәк. Дошман тарафыннан вакытлыча басып алынган совет җиренең зур өлешен азат итәсе бар әле. Ерткыч, көчле, рәхимсез дошман белән эш итәбез без, ул үзе басып алганнарны кулында тотып калу өчен бөтен нәрсәне эшләячәк. Алда—авыр, киеренке, кан коюлы сугышлар тора.

Иптәш Сталин үзенең приказында, дошманга зарар китерелде, немец армиясе кризис кичерә, ләкин ул әле җиңелмәгән, дип күрсәтте. «Кызыл Армия алдында мәкерле, рәхимсез һәм хәзергә әле көчле булган дошманга каршы каты көрәш тора. Бу көрәш вакыт сорый, корбаннар сорый, көчләребезне җигүне һәм барлык мөмкинлекләребезне туплауны сорый. Без Советлар Украинасын немецлар изүеннән азат итә башладык, ләкин миллионнарча украинлылар әле немец кол биләүчеләр изүе астында торалар. Белоруссиядә, Литвада, Латвиядә, Эстониядә, Молдавиядә, Кырымда, Карелиядә әле хәзергә немец оккупантлар һәм аларның ялчылары хуҗалык итә. Дошман армияләренә куәтле ударлар ясалды, ләкин әле дошман җиңелмәгән. Немец басып алучылар ярсынып каршылык күрсәтәләр, контратакаларга күчәләр, оборона чикләрендә тотынып калырга маташалар һәм аларның яңа авантюраларга барулары мөмкин. Менә шуңа күрә дә безнең сафларыбызда тынычлыкка, гамьсезлеккә, масаюга урын булмаска тиеш».

Үз армияңнең, үз дәүләтеңнең реаль көчләрен һәм дошманның көчен аек рәвештә учетка алу, хәзер немец-фашист армиясе кичерә торган кризисның әле дошманның җиңелгәнлеген һәм айный алмаслыгын күрсәтмәгәнлекне аңлау—безнең халкыбызга тагын да зуррак тыйнаклык, армый-талмый эшләргә һәрвакыт әзер тору, тәмам җиңгәнчегә кадәр үз-үзеңне аямыйча сугышырга әзер тору сыйфатларын бирә, аның үз-үзенә таләпчәнлеген арттыра.

Советлар Союзының алдагы көрәшләр өчен җитәрлек кадәр көчләре һәм резервлары, шулай ук уңайлы хәрби-политик шартлары бар. Бу безгә киләчәккә ышаныч белән карарга нигезләр бирә. Бездә җиңү өчен бөтен нәрсә бар. Безнең мөмкинлекләребезне дөрес файдалану һәм тулы җиңүгә ирешү өчен бер генә нәрсә таләп ителә: безнең дәүләтебезнең һәрбер гражданины, халык аны тылда да һәм фронтта да, нинди генә постка, нинди генә эшкә куйса да, ватанны саклау буенча безнең хак эшебезнең тантанасына үзен бөтенләй биреп ватан хакына үз-үзен аямыйча эшләргә тиеш.

Гаскәрләргә бирелгән приказда иптәш Сталин болай ди: «Кызыл Армиянең җиңүләренә бөтен совет халкы шатлана. Кызыл Армиянең сугышчылары, командирлары һәм политработниклары остазыбыз Ленинның: «Беренче эш—җиңү белән мавыкмаска һәм масаймаска, икенче эш — җиңүне үзеңнеке итеп ныгытырга, өченче эш—дошманны кыйнап бетерергә»—дигән васыятьләрен исләрендә нык тотарга тиешләр».

Хәзер безнең халкыбыз алдында, Советлар Союзының кораллы көчләре алдында торган төп бурыч шундый: ерткыч дошманны кыйнап бетерергә, аңа рәхимлелек күрсәтмәскә, аны көнбатышка куарга, бөтен совет җирен кабахәт немец кол биләүчеләрдән азат итәргә!

КОЛХОЗЛАРДА ХЕЗМӘТ РЕЗЕРВЛАРЫННАН ДӨРЕС ҺӘМ ТУЛЫ ФАЙДАЛАНЫРГА

Хәзерге көндә, хезмәт резервларының шактый өлеше фронтка тартылганлыктан, колхозлардагы барлык эш көчләрен ачыклау һәм аларны тулысынча файдалану аеруча әһәмиятле бурыч булып тора. Ә бу көч бездә бик зур. Мин биредә шул көчләрнең кайберләренә генә тукталам.

Сугыш уңае белән Татарстанга байтак кына халык күчеп килделәр. Аларның күпчелеге 1942 нче елда колхоз эшендә актив катнаштылар, күбесе эш нормаларын икешәр тапкыр арттырып үтәделәр. Мәсәлән, Иванова, Давыдова һәм Лузгин (Теләче районы, Зур Нарсы авылыннан) иптәшләр 250 шәр хезмәт көне эшләделәр. Борисова, Шиманова, Альманский һәм Агиев (Красный бор районы, «Маяк» колхозыннан) иптәшләрнең һәркайсы 344—444 әр хезмәт көне эшләделәр.

Мондый мисалларны барлык районнардан бик күпләп китерергә мөмкин. Ләкин кайбер районнарда күчеп килгән халыклардан тулысынча файдаланмыйлар әле. Апас районында күчеп килүчеләрнең 24 проценты, Кукмара районында 27 проценты, Әлки районында 35 проценты, Яңа Чишмә районында 36 проценты бер эшкә дә тартылмаганнар.

1943 нче елда бу кимчелек бетәргә тиеш. Күчеп килгән гражданнарның хезмәткә яраклыларыннан дөрес һәм тулысынча файдалануны оештырырга кирәк.

Күп кенә колхозларда администрация-идарә аппаратлары һаман да әле чиктән тыш кабарынкы. Мәсәлән, Чүпрәле районының «Татарстан» колхозында хезмәткә яраклы колхозчыларның 14 проценты, ә Буденный районының Киров исемендәге колхозында 16 проценты администрация-хуҗалык аппаратында эшләүчеләр. «Татарстан» колхозында тик охранниклар гына да 7 кеше.

Буденный районының Буденный исемендәге колхозының бухгалтериясе 6 кешедән тора. Анда өлкән бухгалтердан башлап учетчикка кадәр аерым кешеләр куелган.

Колхозларда администрация-идарә штатларын ныклап тикшерергә һәм кыскартырга кирәк.

Хезмәт дисциплинасының нык булуы, колхозчылар тарафыннан хезмәт көннәре минимумының үтәлүе хезмәт резервларын бик нык арттыручы чара булып тора. Ләкин безнең Татарстан АССР ның күп кенә колхозларында әһәмиятле бу чара да тиешенчә үтәлми. Хезмәткә яраклы колхозчыларның гомуми саныннан чыгып исәпләгәндә узган елны беренче чорда хезмәткә яраклы колхозчыларның 4,2 проценты, икенче чорда 1,5 проценты, өченче чорда 2,2 проценты бер сәбәпсез хезмәт минимумын үтәмәделәр. Бу, хезмәт дисциплинасын бозучыларга карата вакытында тиешле чара күрелмәүнең нәтиҗәсе булып тора. Югарыда әйтелгән шул ук «Татарстан» колхозында үткән хуҗалык елының беренче чорында 88 кеше, икенче чорында 89 кеше хезмәт минимумын үтәмәделәр. Ләкин шуңа да карамастан, бу колхозда бер генә кеше дә суд җаваплылыгына тартылмаган.

Кайбер колхозларда хезмәт көннәрен учетка алу бик начар куелган. Чүпрәле районының «Татарстан», Буденный районының Буденный исемендәге колхозларында шушы вакытка кадәр колхозчыларның хезмәт көннәре кенәгәләре бөтенләй юк. Чистай районының «Победа № 2» колхозында да учет эшләре начар куелган. Биредә колхозчыларның эшкә чыгу көннәре учетка бөтенләй алынмый.

1943 нче елда мондый хәлләргә килешүчәнлек күрсәтү һич тә ярамый. Хәрби икенче язны үткәргәндә колхозларда эшкә чыкмау фактларын бөтенләй булдырмаска, хезмәт көннәре минимумынын тулысынча үтәлүенә ирешергә кирәк.

Доцент **С. ИЛЬИН.**

Тылда да фронттагыча эшлиләр

Колхоз авылы фронттан калышмыйча, кызу темплар белән язгы чәчүгә әзерләнә. Колхозчыларның яше-карты хәзер шушы эшкә тартылган. Колхоз усадьбасында, тимерчелектә һәм фермаларда кызу эш кайный. Биредә гүзәл эш үрнәкләре күрсәтеп, колхозчыларны намуслы хезмәткә өндәүче ватан сугышы инвалидлары да бар. Алар үзләренең туган авылларына фронт эшчәнлеген һәм инициативасын алып кайтканнар.

Күптән түгел, Кызыл Армия районында, ватан сугышы инвалидларының киңәшмәсе булды. Анда 150 кеше катнашты. Инвалидлар нинди эшләр белән шөгыльләнүләре һәм алдагы көннәрдә дә илебезнең героик хезмәтендә катнашу өчен үзләре башкара ала торган һөнәрләргә өйрәнүләре турында сөйләделәр.

Алар дәүләт тәрбиясендә тик кенә ятарга теләмиләр. Кулларыннан килгән эштә катнашып ватанга хезмәт күрсәтергә телиләр. Менә Кадиров һәм Грачев иптәшләр. Аларның берсе район башкарма комитеты председателенең урынбасары. Ә икенчесе район җир бүлеге мөдире. Районда сугыштан кайткан 8 инвалид колхоз председателе булып эшлиләр. Тагын күп кенә иптәшләр хисапчылык эшен башкаралар. «Канаш» колхозы председателе иптәш Ефимов колхозның эшен фронттагыча оештыра алды. Аның чәчү орлыгы бар. Машиналар кырда эшләргә бүгеннән әзер. Тирес чыгару һәм ашламалар җыю планы да үтәлгән. Хәзер иптәш Ефимов үзенең колхозчылары белән «Пятилетка» колхозына булыша.

Инвалидлар арасында авыр эшләрне башкара алмаучылар да бар. Ләкин алар да эшсез торырга теләмиләр. Киңәшмә ул иптәшләрне эшкә өйрәтергә кирәклекне әйтте. Алар өчен хисапчылар курслары һәм җиңел һөнәрләргә өйрәтү түгәрәкләре оештыру чараларын билгеләде.

— Без ватан сугышында азатлык өчен көрәшкәндә сәламәтлегебез кимеде. Ләкин бу безнең күңелебезне төшерми. Калган көчебезне дә үзебезне тәрбияләүче дәүләтебезгә бирергә әзер торабыз — диләр ватан сугышы инвалидлары.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

28 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

ләрны килү белән үк сугышка кертәләр. Бер участокта безнең сугышчылар гитлерчыларның 5 контратакасын кире кайтардылар, дошманның 8 танкысын зарарладылар һәм яндырдылар. Икенче бер участокта халык яши торган бер пункт өчен бөтен көн буена каты көрәш барды. Бу пункт берничә тапкырлар кулдан-кулга күчте. Кичкә таба совет подразделенияләре анда нык кереп урнаштылар. Сугыш кырында дошманның 500 дән артык үле гәүдәләре, җимерелгән 13 танкысы һәм күп автомашиналары калды.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары, кискен атака нәтиҗәсендә, халык яши торган ике зур пунктны алдылар. Бер артиллерия складын һәм бер ашлык складын кулга төшерелде. Безнең бер группа танкларыбыз шоссе юлына барып чыктылар һәм дошманның чигенү юлын кистеләр. Немецларның шунда килеп җиткән бер пехота батальоны бөтенләй диярлек юк ителде. 9 орудие, төрле йөкләр төялгән 17 автомашина һәм 36 повозка кулга төшерелде. Пленныйлар алынды.

* * *

Курскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышларын дәвам иттерделәр. Халык яши торган зур бер пунктка килү юлларында Н-че часть өч көн инде дошманга каршы бик каты сугышлар алып бара. Шул вакыт эчендә ике батальоннан артык гитлерчылар юк ителде. Бик күп трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Витебск өлкәсендә хәрәкәт итүче бер отрядның бер группа партизаннары февраль урталарында юлдан килә торган немецлар обозына кинәт һөҗүм иткәннәр. Партизаннар 30 гитлерчыны кырып ташлаганнар һәм сугыш припаслары төялгән 6 олауны юк иткәннәр. Партизаннарның икенче бер группасы халык яши торган бер пунктта немецлар гарнизонын тар-мар иткән. Совет патриотлары бер азык складын яндырганнар һәм 20 гитлерчыны кырып ташлаганнар.

Минск партизаннарының бер отряды бер тимер юл станциясендә дошманның товар базасын һәм азык складын яндырган.

* * *

Немецларның 299 нчы пехота дивизиясенең 528 нче полкының 11 нче ротасыннан плен алынган обер-ефрейтор Эвальд Пихлер болай диде: «Безнең полк тәртипсез рәвештә чигенде һәм авыр югалтуларга дучар булды. Подразделениеләр барысы да диярлек үзләренең коралларын һәм автомашиналарын ташлап калдырдылар. 13 нче пехота орудиеләре ротасы калган 6 пушкасын шартлатты. 3 батальоннан үтерелүчеләр генә дә 300 дән артык булды. Көнчыгыш фронтта немец гаскәрләренең уңышсызлыклары һәм җиңелүләре солдатларның бер өлеше арасында төшенкелек настроениеләре тудырды. Рус гаскәрләренең Сталинград янында немецларның 6 нчы армиясен чолгап алганлыкларын һәм юк иткәнлекләрен белгәннән бирле без һаман куркуда яшибез. Безгә, һәрвакытта да, без чолганып алынганбыз һәм безне Сталинград янында тар-мар ителгән немец дивизияләре язмышы көтә кебек күренә. Үз-үзебезгә ышанмыйбыз. Күп солдатлар инде, немец армиясе русларга каршы тора алмас, дип саныйлар».

* * *

Греция партизаннарының Греция армиясе полковнигы җитәкчелегендәге зур бер отряды Калабакида оккупантлар гарнизонына һөҗүм иткән. Өч көн буена барган сугышларда Греция патриотлары дошманны зур югалтуларга дучар иткәннәр. Партизаннар шәһәрне алганнар һәм 50 немец һәм итальян солдатын плен алганнар.

1 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

Шушы көннәрдә Төньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре дошман гаскәрләренең Демянск группасына каршы һөҗүмгә күчтеләр. Сугышларның 8 көне эчендә безнең гаскәрләр халык яши торган 302 пунктны, шул исәптән **Демянск** шәһәрен һәм район үзәкләреннән **Лычковоны, Залучьены** азат иттеләр.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

28 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 4 артиллерия батареясының утын бастырдылар һәм бер сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак Н-че берләшмә частьлары немецларның бик күп ныгытмаларын һәм терәк пунктларын алдылар. Бер участокта гына да совет подразделениеләре дошманның 26 ДЗОТ ын һәм блиндажын җимерделәр, 8 орудиесен һәм дистәләрчә пулемет точкаларын юк иттеләр. Гитлерчылар, югалткан позицияләрен кире кайтарырга маташып, контратака ясап карадылар, ләкин алып ташландылар. Сугыш кырында дошман 200 гә якын үле гәүдә һәм сафтан чыгарылган 2 танк калдырды.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең частьлар дошманның контратакаларын кире кайтардылар, ә көчләрнең бер өлеше сугыш белән разведка алып барды. Безнең танк подразделениеләре һәм моторлаштырылган подразделениеләр немецларның бер батальонга якын пехотасын юк иттеләр, дошманның 5 танкысын, сугыш припаслары төялгән 15 автомашинасын һәм бензин тутырылган 4 автоцистернасын зарарладылар һәм яндырдылар. Икенче бер участокта Н-че часть сугышчылары 2 сугыш припаслары складын, бер азык складын, 5 орудие, 8 миномет, 11 пулемет һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Пленныйлар алынды.

* * *

Кубаньда безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че часть сугышчылары, тиздән су һәм пычрак ерып алга барып, дошманның көчле итеп ныгытылган позицияләрен алдылар һәм 7 орудие, 18 пулемет, 5 миномет, 2 сугыш припаслары складын, 40 ат һәм 19 трактор кулга төшерделәр. Сугыш кырында дошманның 300 гә якын үле гәүдәләре калды. Фронтның икенче бер участогында немецларның 3 танкысы һәм 2 бронемашинасы юк ителде.

* * *

Украинаның бер районында хәрәкәт итүче партизаннарның зур отряды 20 нче февральдә бер үк вакытта берничә тимер юл станциясенә һөҗүм иткән. Партизаннар немец сакчыларны кырып ташлаганнар һәм станция корылмаларын җимергәннәр. Бер тимер юл станциясендә депо һәм ярдәмче мастерскойлар шартлатылган, 9 паровоз, ягулык, азык һәм агач материаллары складлары юк ителгән. Зур тимер юл узелының электр станциясе сафтан чыгарылган. Икенче бер станциядә партизаннар гаражны, 5 автомашинаны, 2 телефон станциясен, бер азык складын һәм хәрби частьның пекарнясен юк иткәннәр. Дошманга каршы сугышта совет патриотлары 80 немец солдатын һәм офицерын юк иткәннәр. 3 пулемет, 84 винтовка, 3 пистолет, 1.200 патрон, 40 комплект киемнәр һәм башка төрле сугыш милекләре һәм снаряжениеләр кулга төшерелгән. Партизаннарга 88 гитлерчы пленга бирелгән.

* * *

Немец-фашист кабахәтләр, Харьков өлкәсенең Рогань поселогыннан чигенер алдыннан, 16 кешене атып үтергәннәр. Шуның өстенә фашист палачлар совет хатын-кызларыннан 9 кешене — ике бала анасы булган Марфа Брединаны, 23 яшьлек Мария Горгульны, 24 яшьлек Ольга Бельцеваны һәм башкаларны асканнар.

* * *

Бельгия патриотлары Шарлеруа районында немецларның бер хәрби эшелонын һәлак итүне оештырганнар. 20 дән артык вагон җимерелгән. Һәлакәт вакытында 100 дән артык гитлерчы үлгән һәм яраланган. Антверпенда бер группа кораллы бельгиялеләр немецлар часте штабына барып кергәннәр, 7 гитлерчыны үтергәннәр һәм яшерен документларны кулга төшергәннән соң бинаны шартлатканнар.

1 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

1 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошманга каршы ут сугышы алып бардылар. Безнең артиллерия һәм минометлар уты белән немецларның күп сандагы ДЗОТ лары, 3 артиллерия батареялары, 5 минометлары һәм 18 пулемет точкалары юк ителде. Н-че часть сугышчылары дошманның бер рота пехотасын тар-мар иттеләр, 3 бронемашинасын җимерделәр һәм сугыш припаслары һәм төрле кирәк-яраклар төялгән 15 автомашиналарын юк иттеләр.

Безнең авиациябез тарафыннан һава сугышларында һәм шулай ук зенит артиллериясе уты белән немецларның 16 самолеты бәреп төшерелде.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак Н-че часть немец пехотасының контратакасын кире кайтарды һәм, чигенүче гитлерчыларны куып барып, халык яши торган бер пунктны алды. 100 дән артык немец солдаты һәм офицеры үтерелде. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган күп кенә пунктлар алдылар. Халык яши торган бу пунктларның берсе өчен барган сугышларда гына да дошманның 2 ротасы тар-мар ителде. Трофейлар кулга төшерелде. Алар арасында элемтә полкы җиһазлары төялгән 23 автомашина бар. Икенче бер участокта Н-че частьның сугышчылары, дошманның каты каршылык күрсәтүләрен сындырып, алга киттеләр, трофейлар кулга төшерделәр һәм пленныйлар алдылар

* * *

Курскидан көнбатыштарак безнең частьлар һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны азат иттеләр. Бер участокта немецлар контратака ясадылар, ләкин, сугыш кырында 200 гә якын үле гәүдәләрен калдырып, алып ташландылар. 3 орудие, эре калибрлы 2 пулемет, 6 миномет һәм сугыш припаслары складын кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең частьлар тарафыннан 5 артиллерия складын һәм 500 тоннага якын бодай һәм солы тутырылган азык-фураж складын алынды.

* * *

Украина районнарының берсендә хәрәкәт итүче «За родину» отряды партизаннары бик әһәмиятле тимер юл магистрале янына урнашкан халык яши торган бер пункт өчен барган сугышларда 100 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырып бетерганнәр. Украинадагы икенче бер отрядның партизаннары группасы дошманның 2 хәрби эшелонын юлдан чыгарган. 2 паровоз һәм 49 вагон җимерелгән.

* * *

Немецларның 4 нче тау укчылар дивизиясенең 13 нче полкыннан пленга төшкән солдат фриц Кайзер болай дип белдерде: «Безнең дивизия чигенүне дәвам итә. Кай җирдә туктаячагыбызны беркем дә белми. Ягулык җитмәгәнлектән командование автотранспортның 60 процентын яндыру турында приказ бирде. Коралларыбызның, сугыш припасларыбызның һәм кыйммәтле җиһазларның күп өлешен юк итәргә өлгерә алмадык, һәм алар руслар кулына төште. Кавказда, Кубаньда Германия армиясенең җиңелүләре уңае белән солдатларның рухы төште. Озакка сузылган сугыштан ризасызлык күрсәткән сөйләшүләрне бик еш очратырга мөмкин. Күптән түгел обер-ефрейтор Штерн әләкләве буенча русларга плен төшәргә үзара киңәшкән 3 солдатны һәм унтер-офицерны аттылар. Берничә көннән соң обер-ефрейтор Штернның үле гәүдәсе табылды».

* * *

Немец-фашист кабахәтләр Ворошилов өлкәсе, Ново-Светловка авылы гражданнарыннан канлы үч алганнар. Гитлерчы палачлар бөтен бер семьяларны алып чыкканнар һәм атканнар. Атылучылар арасында Мария Бондаренко, Пелагея Бондаренко һәм аның 5 яшьлек улы, Иван Хмельницкий, Екатерина Хмельницкая һәм башка кешеләр бар. Газапланган һәм атылган кешеләрнең гәүдәләрен гитлерчылар авыл уртасындагы зур чокырга аударганнар. Немец-фашист палачлар кулыннан барлыгы 150 дән артык тыныч совет гражданнары һәлак булган.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ 25 ЕЛЛЫГЫ ТУРЫНДА ИРАН МАТБУГАТЫ

ТАҺРАН, 25 февраль. (ТАСС). Иран газеталары, Кызыл Армиянең 25 еллыгына багышлап, бик күп мәкаләләр яздылар. «Раһбар» газетасы Кызыл Армия оештырылганнан бирле аның үткән сугышчан юлын күрсәтеп, болай дип яза: «Хәзерге көндә совет гаскәрләре бөтен дөньяда азатлык сөюче халыкларның киләчәк тормышы өчен геройларча көрәшеп, бөек бурычны үтиләр».

«Бахтер» газетасы, Кызыл Армия бәйрәме фронтларда аның тарафыннан ирешелгән бик зур җиңүләр белән бергә туры килде, дип яза.

«Журнал де Тегран» газетасы совет сугышчыларының батырлыгына сокланганлыгын белдереп, болай ди: «Кызыл Армия үзенең җирен геройларча саклый. Ул, хокукның һәм гаделлекнең кадерен белүче барлык кешеләрнең симпатиясе белән файдалана».

ТУНИСТА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 28 февраль. (ТАСС). Союзникларның Төньяк Африкадагы көчләре штабының белдерүендә әйтелүенчә, союзникларның гаскәрләре Төньяк Тунистагы киң фронтта дошманның атакаларын кире кайтарганнар. Кассерин районында дошман чигенүдә дәвам итә. 26 нчы февральдә союзниклар авиациясе Сицилиядән көньяктарак дошманның бер кораблен батырган һәм 3 кораблен яндырган.

Марокко радиосының хәбәр итүенә караганда, Франция гаскәрләре генерал Жиро командалыгында Сбива секторында (Кассериннан 30 километр төньяк-көнчыгышта) 25 километрга алга барганнар.

Америка бомбардировщикларының Брестка һөҗүме

ЛОНДОН, 28 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 27 нче февральдә көндез Американың «Оча торган крепость» һәм «Либерейтор» бомбардировщиклары Бресттагы порт корылмаларына һөҗүм ясаганнар. Англия истребительләре бу операцияләрнең алып барылуын саклап торганнар.

Шул ук көнне «Вентура» бомбардировщиклары Дюнкерк докларына һөҗүм ясаганнар. Пристаньга һәм корабльләргә бомбалар төшкән. Бу операцияләрнең алып барылуын Англия һәм Америка истребительләре саклап торганнар.

ГРЕЦИЯДӘ НЕМЕЦЛАРНЫҢ КОТОЧКЫЧ ЕРТКЫЧЛЫГЫ

ЛОНДОН, 28 февраль. (ТАСС). Күптән түгел Саламин атавында шартлау булган һәм шуның нәтиҗәсендә Германиянең 5 солдаты үтерелгән. Бер үк вакытта Германиянең бер пароходында шартлау булган. Германия властьлары бу шартлауларда Греция патриотларын гаепләп, политик тоткыннардан йөзләрчә заложникларга ерткычларча җәза биргәннәр. Гитлерчы палачлар Германия солдатларын төз атуга өйрәткән вакытта, заложниклардан тере мишень сыйфатында файдаланганнар.

Җаваплы редактор И. УЗБЕКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность - транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ1067 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 344